# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Биектау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16 ноябрь 2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендәТатарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Биектау торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 16 ноябрендә 10:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Биектау торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Биектау авылы Тынычлык урамындагы юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю.

2.Биектау авылы зиратларын койма белән әйләндереп алу.

3. Биектау авылындагы су башнясы өчен тирәнлек насосларын сатып алу, ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү

4.Янгын автомашинасын карап тоту, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

5.Биектау авылында янгын сүндерү автомобиле өчен су алу җайланмасын урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 133 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 74 кеше, бу 56% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 74 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Биектау торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Биектау торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Биектау авылы Тынычлык урамындагы юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю.

2. Биектау авылы зиратларын койма белән әйләндереп алу.

3. Биектау авылындагы су башнясы өчен тирәнлек насосларын сатып алу, ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү

4.Янгын автомашинасын карап тоту, янгын автомашинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

5. Биектау авылында янгын сүндерү автомобиле өчен су алу җайланмасын көйләү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында<br>
рәислек итүче,<br>
Авылҗирлегебашлыгы Ф.М.ШАКИРОВ